**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ РЫБНО-СЛОБОДСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

422650, пгт. Рыбная Слобода,
ул. Ленина, дом 48

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛЫК БИСТӘСЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

422650, Балык Бистәсе,
Ленин урамы, 48 нче йорт

Тел.: (84361) 22113, факс: (84361) 23012, e-mail: balyk-bistage@tatar.ru, сайт: ribnaya-sloboda.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

01.09.2015 Балык Бистәсе штп. № 232пи

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында халык дружиналары эшчәнлеген координацияләү буенча район штабы турында

«Гражданнарның җәмәгать тәртибен саклауда катнашуы турында» 2014 елның 2 апрелендәге 44-ФЗ номерлы Федераль законны һәм «Татарстан Республикасында гражданнарның җәмәгать тәртибен саклауда катнашуы турында» 2015 елның 16 гыйнварындагы 4-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын гамәлгә ашыру максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында халык дружиналары эшчәнлеген координацияләү буенча республика штабы турында» 2015 елның 18 апрелендәге 702-р номерлы карары, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уставы нигезендә карар бирәм:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында халык дружиналары эшчәнлеген координацияләү буенча район штабы булдырырга.

2. Расларга:

-Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында халык дружиналары эшчәнлеген координацияләү буенча район штабы турында нигезләмәне;

- Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында халык дружиналары эшчәнлеген координацияләү буенча район штабы составын .

3. Үз көчен югалткан дип танырга:

-Балык Бистәсе муниципаль районы башкарма комитетының «Халык дружинасы штабы составын раслау турында» 2008 елның 17 декабрендәге 209пи номерлы карары;

-Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының «Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең «Халык дружинасы штабы составын раслау турында»17.12.2008 ел, № 209 пи карарына үзгәрешләр кертү хакында " 2009 елның 17 сентябрендәге 150пи номерлы карары;

-Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының «Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең «Халык

дружинасы штабы составын раслау турында»17.12.2008 ел, № 209 пи карарына үзгәрешләр кертү хакында " 2010 елның 20 июлендәге 125пи номерлы карары;

-Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының «Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең «Халык дружинасы штабы составын раслау турында»17.12.2008 ел, № 209 пи карарына үзгәрешләр кертү хакында " 2010 елның 23 ноябрендәге 251пи номерлы карары;

-Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының «Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең «Халык дружинасы штабы составын раслау турында»17.12.2008 ел, № 209 пи карарына үзгәрешләр кертү хакында " 2011 елның 14 апрелендәге 97пи номерлы карары;

-Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының «Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең «Халык дружинасы штабы составын раслау турында»17.12.2008 ел, № 209 пи карарына үзгәрешләр кертү хакында " 2012 елның 11 сентябрендәге 245 пи номерлы карары;

-Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының «ТР Балык Бистәсе муниципаль районы буенча халык дружинасы турында Нигезләмәне раслау хакында»2013 елның 11 мартындагы 45пи номерлы карары.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Интернет-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru веб-адресы буенча, Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы» нда http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча урнаштырырга.

4.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Җитәкче вазифаларын башкаручы Р.Х.Хәбибуллин

Балык Бистәсе муниципаль
районы Башкарма комитетының 2015
елның 1 сентябрендәге 232 пи
номерлы карары белән расланган

**Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында халык дружиналары эшчәнлеген координацияләү буенча район штабы турында нигезләмә**

1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында халык дружиналары эшчәнлеген координацияләү буенча район штабы (алга таба - район штабы) Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы территориясендә халык дружиналары эшчәнлеген координацияләү һәм аларның җирле үзидарә органнары, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарының территориаль органнары, эчке эшләр органнары (полиция) һәм башка хокук саклау органнары белән үзара хезмәттәшлеге максатларында оештырылган даими эшләүче коллегиаль орган булып тора.

1.2. Район штабы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты тарафыннан оештырыла.

1.3. Район штабы үз эшчәнлегендә Россия Федерациясе Конституциясенә, федераль законнарга, Татарстан Республикасы Конституциясенә, Татарстан Республикасы законнарына, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уставына, башка муниципаль хокукый актларга, шулай ук әлеге Нигезләмәгә таяна.

2. Район штабының төп бурычлары

2.1. Район штабының төп бурычлары булып тора:

а) Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының халык дружиналары эшчәнлеге турындагы мәгълүматны гомумиләштерү һәм анализлау, аерым халык дружиналары эшчәнлегенең уңай тәҗрибәсен тарату, Татарстан Республикасында үткәрелә торган өйрәтү семинарларында халык дружиналары командирларының катнашуын оештыру;

б) җәмәгать тәртибен саклау мәсьәләләре буенча дәүләт органнарына, җирле үзидарә органнарына һәм хокук саклау юнәлешендәге иҗтимагый берләшмәләргә тәкъдимнәр кертү.

3. Район штабының төп функцияләре

3.1. Район штабының төп функцияләре булып тора:

а) Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының халык дружиналары эшчәнлеген координацияләү һәм алар белән эчке эшләр органнарына (полициягә) һәм башка хокук саклау органнарына җәмәгать тәртибен саклауда ярдәм итү мәсьәләләре буенча хезмәттәшлек итү;

б) Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының халык дружиналары эшчәнлеген координацияләүгә бәйле мәсьәләләрне һәм тәкъдимнәрне карау;

в) халык дружиналары командирларының һәм аларның урынбасарларының таныклыкларын рәсмиләштерү, бирү һәм алыштыру;

г) Балык Бистәсе муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштыруны тәэмин итү, шулай ук хәбәрсез югалган затлар турында массакүләм мәгълүмат чараларында, аларны эзләү урыны, хәбәрсез югалган

затларны эзләү буенча чаралар координаторларының контакт мәгълүматлары, хәбәрсез югалган затларны эзләү өчен кирәкле бүтән халыкка мәгълүм булган мәгълүматларны эзләү урыннарында хәбәрсез югалган затларны табуны тәэмин итү;

д) халык дружиналары командирларыннан халык дружиналарының эш нәтиҗәләре турында мәгълүмат сорату;

е) җирле үзидарә органнарына хокук тәртибен ныгыту, халык дружиналары эшен камилләштерү буенча тәкъдимнәр кертү;

ж) үз вазыйфаларын башкарганда аерылып торган халык дружинникларын бүләкләү турында Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарына, җирле үзидарә органнарына һәм хокук саклау органнарына тәкъдимнәр җибәрү.

## 4. Район штабы вәкаләтләре

4.1. Район штабы үз компетенциясе чикләрендә хокуклы:

а) Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында федераль башкарма хакимият органнарының территориаль органнарыннан, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында дәүләт хакимияте башкарма органнарының территориаль органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан, халык дружиналарыннан, оешмалардан үзенә йөкләнгән бурычларны үтәү өчен кирәкле белешмәләрне соратып алырга;

б) үз утырышларына Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында дәүләт хакимияте башкарма органнарының территориаль органнары, җирле үзидарә органнары һәм халык дружиналары вәкилләрен халык дружиналары эшчәнлеге турында фикер алышканда чакырырга;

в) билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында башкарма хакимиятнең территориаль органнары вазыйфаи затларын һәм белгечләрен, шулай ук халык дружиналарына йөкләнгән бурычларны гамәлгә ашыруда практик ярдәм күрсәтү өчен оешмаларны җәлеп итәргә;

г) халык дружиналары эшчәнлеген камилләштерү буенча тәкъдимнәр җибәрергә.

## 5. Район штабы эшчәнлеген оештыру

5.1. Район штабын штаб начальнигы җитәкли, ул аның эшен оештыра.

5.2. Район штабы үз эшчәнлеген әлеге Нигезләмә һәм эш планы нигезендә алып бара. Район штабының эш планы аның әгъзаларының тәкъдимнәре нигезендә бер елга төзелә һәм штаб начальнигы тарафыннан раслана.

5.3. Район штабы утырышлары кирәк булганда ярты елга бер тапкыр үткәрелә.

5.4. Район штабы утырышларын район штабы начальнигы яки аның кушуы буенча аның урынбасары үткәрә.

5.5. Район штабы утырышының көн тәртибе чираттагы утырышны үткәрүгә ун көн кала эш планы нигезендә район штабы секретаре тарафыннан формалаша.

5.6. Район штабы утырышын үткәрү датасын һәм вакытын штаб начальнигы, ул булмаган очракта - штаб башлыгы урынбасары билгели. Район штабы әгъзалары утырышның датасы һәм көн тәртибе турында район штабы секретаре тарафыннан чираттагы утырышны үткәргән көнгә кадәр биш эш көненнән дә соңга калмыйча хәбәр ителә.

5.7. Район штабы секретаре кергән материалларны җыеп гомумиләштерә, район штабы карары проектын формалаштыра. Утырышлар үткәрү материаллары һәм карар проекты район штабы секретаре тарафыннан район штабы башлыгына билгеләнгән утырышка өч көн кала тапшырыла.

5.8. Район штабы утырышы, составының яртысыннан да ким булмаган очракта, хокуклы санала.

5.9. Район штабы начальнигы, аның урынбасары, секретаре һәм район штабы әгъзалары утырышларда шәхсән катнашалар.

5.10. Район штабы карарлары ачык тавыш белән кабул ителә һәм алар өчен утырышта катнашучы әгъзаларның яртысыннан артыгы тавыш бирсә, кабул ителгән дип санала. Район штабы әгъзалары тавышлары тигез булганда, утырышта рәислек итүче тавышы хәлиткеч тавыш булып тора.

5.11. Район штабы карары беркетмә белән рәсмиләштерелә һәм утырышта рәислек итүче һәм район штабы секретаре тарафыннан имзалана. Район штабы әгъзаларының аерым фикере язмача языла һәм район штабы карарына кушыла.

5.12. Район штабы документларын саклау һәм файдалану секретарь тарафыннан башкарыла.

5.13. Район штабы эшчәнлеген матди-техник яктан тәэмин итү Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты тарафыннан башкарыла.

Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының 2015 елның 01 сентябрендәге № 232 пи карары белән расланган

**Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында халык дружиналары эшчәнлеген координацияләү буенча район штабы составы**

| | |
|---|---|
| Хәбибуллин Рашат Хәбри улы | Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфаларын башкаручы-Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары, штаб башлыгы |
| Мөхәммәтҗанов Ренат Гомәр улы | Россия Эчке эшләр министрлыгының Балык Бистәсе районы буенча бүлегенең җәмәгать тәртибен саклау буенча полиция башлыгы урынбасары, штаб башлыгы урынбасары (килешү буенча) |
| Наумова Татьяна Александровна | Балык Бистәсе муниципаль районы Балык Бистәсе шәһәр җирлеге башкарма комитетының әйдәп баручы белгече, штаб секретаре (килешү буенча) |
| Штаб әгъзалары: | |
| Вәлиев Марат Мансур улы | Балык Бистәсе муниципаль районы Балык Бистәсе шәһәр җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфаларын башкаручы (килешү буенча) |
| Хәбибуллин Ленар Рафаэл улы | Балык Бистәсе районы буенча Россия ЭЭМ бүлегенең УУП һәм ПДН бүлеге башлыгы (килешү буенча) |
| Кадыров Динар Габдрафик улы | Балык Бистәсе муниципаль районы Башлыгының мобилизацион эш буенча ярдәмчесе, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Советы Аппараты һәм Башкарма комитетының халык дружинасы командиры (килешү буенча) |
| Җамалиев Рәсим Бәдретдин улы | Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының гомуми бүлеге начальнигы |
| Төхвәтуллин Васил Йосыф улы | “Балык Бистәсе агротехника техникумы " ГАПОУ директоры (килештерү буенча) |
| Ненастьев Евгений Александрович | Балык Бистәсе муниципаль районы " Форпост» җәмәгать тәртибен саклау буенча яшьләр (мәктәпләр) формированиеләре үзәге директоры |